ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.08.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2200**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 2495 номерлы карары белән расланган, спорт хөкемдарына квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Спорт спорт хөкемдарлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 28 февралендәге 134 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 2495 номерлы карары белән расланган, спорт хөкемдарына квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.4.4 пунктчасын өстәргә:

«2.4.4. Кабул ителгән карар турындагы документның күчермәсе, имза салынган көннән алып 10 эш көне эчендә, региональ спорт федерациясенә, исемлеккә кертелгән физкультура-спорт оешмасына җибәрелә һәм (яисә) оешманың "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла;

1.2. Административ регламентның 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.4.5 пунктчасын өстәргә:

«2.4.5. Квалификация категориясен бирү өчен спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмәнең 27, 28.1, 29, 29.1 пунктларында каралган таләпләргә туры килми торган документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, оешмалар тарафыннан документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителә»;

1.3. Административ регламентның 2.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Квалификация категориясен бирү өчен документларны карау, аларны теркәгән көннән алып, 16 эш көне тәшкил итә. Квалификация категориясен бирү яки бирүдән баш тарту турындагы карар квалификация категориясе бирү өчен документларны карау йомгаклары буенча 3 эш көне эчендә кабул ителә.

Квалификация категориясе бирү турындагы карар оешманың оештыру-күрсәтмә акты белән рәсмиләштерелә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин